**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6152**
**07.11.2022**

2023 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф оешмаларын финанслау нормативларын исәпләү тәртибен раслау турында» 2020 елның 27 мартындагы 1541 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 2023 елга расларга:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны кушымтада каралганча;

2) сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга төзәтмә кертү коэффициентын 0,65 күләмендә.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны әлеге карарның 1 пунктында каралган норматив чыгымнарга туры китереп тәэмин итәргә.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2022 елның 7 ноябрендәге
6152 номерлы карарына
кушымта

2023 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль дислокациясе | Норматив чыгымнар (елына 1 укучыга сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык укыту срогы | дүрт еллык укыту срогы | биш еллык укыту срогы | җиде еллык укыту срогы | иртә һөнәри юнәлеш бирү |
| Музыка сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 74 988 | 85 669 | 110 026 |
| Сынлы сәнгать | шәһәр җирлеге | | 39 699 | | 35 247 | 84 588 |
| Хореография сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 83 632 | 68 869 | 252 446 |
| Гомуми эстетика сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 35 168 | | |
| Фольклор сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 76 896 | 73 832 | 118 624 |
| Эстрада-джаз сәнгате | шәһәр җирлеге | 115 796 | | 111 004 | | 182 027 |
| Театр сәнгате | шәһәр җирлеге | 59 697 | | 55 573 | 55 492 | 83 712 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева